КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ПО ОХРАНЕ ОБЪЕКТОВ
КУЛЬТУРНОГО НАСЛЕДИЯ

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ МӘДӘНИ
МИРАС ОБЪЕКТЛАРЫН
САКЛАУ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

04.05.2026 № 240-П

Казан ш.

Татарстан Республикасы Мәдәни мирас объектларын саклау комитетының «Татарстан Республикасы Мәдәни мирас объектларын саклау комитетының дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе турында» 2023 елның 29 сентябрендәге 582-П номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

Б о е р ы к б и р ә м:

Татарстан Республикасы Мәдәни мирас объектларын саклау комитетының «Татарстан Республикасы Мәдәни мирас объектларын саклау комитетының дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе турында» 2023 елның 29 сентябрендәге 582-П номерлы боерыгына (Татарстан Республикасы Мәдәни мирас объектларын саклау комитетының 2024 елның 9 июлендәге 327-П номерлы, 2026 елның 4 февралендәге 52-П номерлы боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге боерык белән расланган Татарстан Республикасы Мәдәни мирас объектларын саклау комитетының дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе турында нигезләмәдә:

6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Комиссия Комитетның норматив хокукый акты нигезендә төзелә. Әлеге акт белән Комиссия составы һәм аның эш тәртибе раслана, Комиссия рәисе, аның урынбасары, секретаре билгеләп куела һәм Комиссиянең башка әгъзалары билгеләнә. Комиссиянең барлык әгъзалары карарлар кабул иткәндә тигез хокукларга ия. Комиссия рәисе булмый торганда аның вазыйфаларын Комиссия рәисе урынбасары башкара.»;

7 пунктның «а» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) дәүләт органы җитәкчесе урынбасары (Комиссия рәисе), дәүләт органында дәүләт хезмәте вазыйфасын биләүче зат (Комиссия рәисе урынбасары), дәүләт органының коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча кадрлар хезмәте бүлекчәсе җитәкчесе яисә дәүләт органының коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы кадрлар хезмәте вазыйфаи заты (Комиссия секретаре), дәүләт хезмәте һәм кадрлар мәсьәләләре бүлекчәсеннән, юридик (хокукый) бүлекчәдән, башка бүлекчәләрдән дәүләт органы җитәкчесе тарафыннан билгеләнә торган дәүләт хезмәткәрләре;»;

9 пунктның икенче җөмләсен төшереп калдырырга;

15 пунктның «а» пунктчасының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«дәүләт хезмәткәре тарафыннан Татарстан Республикасы Президентының 2009 елның 30 декабрендәге ПУ-702 номерлы указы белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләр турында белешмәләр бирү хакындагы нигезләмәдә каралган белешмәләрне төгәл яисә тулы итеп тапшырмавы турында;»;

30 пунктның «а» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) Татарстан Республикасы Президентының 2009 елның 30 декабрендәге ПУ-702 номерлы указы белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләр турында белешмәләр бирү хакындагы нигезләмәгә туры китереп, дәүләт граждан хезмәткәре тарафыннан тапшырылган белешмәләрнең төгәл һәм тулы булуын билгеләргә;»;

әлеге боерык белән расланган Татарстан Республикасы Мәдәни мирас объектларын саклау комитетының дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе составын яңа редакциядә (кушымта итеп бирелә) бәян итәргә.

Рәис И.Н.Гущин

Татарстан Республикасы Мәдәни
мирас объектларын саклау
комитетының 29.09.2023 ел,
№ 582-П номерлы боерыгына
2 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Мәдәни
мирас объектларын саклау
комитетының 04.05.2026 ел,
№ 240-П боерыгы редакциясендә)

Татарстан Республикасы Мәдәни мирас объектларын саклау комитетының дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе составы

Комиссия рәисе

| | |
|---|---|
| Камалетдинова Гөлия Фидаил кызы | - Татарстан Республикасы Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты (алга таба – Комитет) рәисе урынбасары |

Комиссия рәисе урынбасары

| | |
|---|---|
| Җәләлетдинова Гөлнара Рәфыйк кызы | - Комитетның дәүләт күзәтчелеге (контроль) һәм суд-административ практика бүлеге башлыгы |

Комиссия секретаре

| | |
|---|---|
| Шәймиева Зөлфирә Кәбир кызы | - Комитетның хокукый, кадрлар, мобилизация һәм оештыру эшләре бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе, коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы зат |

Комиссия әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Словцова Анжела Олеговна | - Комитетның хокук, кадрлар, мобилизация һәм оештыру эшләре бүлеге башлыгы |
| Мостафин Роберт Рамил улы | - «Татарстан Мәдәни мирас үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе җитәкчесе урынбасары |
| Нургалиева Розалия Миргалим кызы | - Татарстан Республикасы Дәүләт сынлы сәнгать музее директоры, Татарстан Республикасы Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты каршындагы Иҗтимагый совет әгъзасы (килешү буенча) |
| Панкратов Алексей Юрьевич | - Татарстан Республикасы Рәисенең Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсенең оештыру бүлеге мөдире (килешү буенча) |

».